**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

13.04.2020 481-п

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә раслау хакында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар уздыруның кушымтада бирелгән бертөр тәртибен һәм шартларын расларга.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының түбәндәге боерыкларын гамәлдән чыккан дип танырга:

«Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2012 елның 10 сентябрендәге 351-п номерлы;

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 10 сентябрендәге 351-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 23 октябрендәге 494-п номерлы;

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 10 сентябрендәге 351-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан

Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 24 октябрендәге 625-п номерлы;

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 10 сентябрендәге 351-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 21 гыйнварындагы 32-п номерлы;

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 10 сентябрендәге 351-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 18 июлендәге 657-п номерлы.

4. Хокукый тәэминат бүлеге башлыгына (М.М.Шәеховка) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Т.Р.Гыйлаҗевка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 13.04.2020 № 481-п боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» РФ Законы), «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – җир асты байлыклары турында ТР Законы), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә эшләнде.

1.2. Нигезләмә гомумтаралган файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару яки гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару хокукын бирү буенча аукционнар (алга таба – Аукционнар) әзерләү һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.3. Аукционнар үткәрү, аукцион комиссияләренең составы һәм эш тәртибе, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү яки бирүдән баш тарту, җир асты байлыкларының һәр кишәрлегенә яки җир асты байлыклары кишәрлекләре төркеменә карата аукционнар үткәрү тәртибен һәм шартларын билгеләү, аукционнар үткәрү өчен кирәкле материаллар һәм мәгълүмат әзерләү, аукционнар оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан башкарыла.

1.4. Үткәрелә торган аукционнар формасы турындагы карар коллегиаль орган – Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының (алга таба – Министрлык) Фәнни-техник советы тарафыннан кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.

## 2. Аукционнарга куела торган җир асты байлыклары кишәрлекләре

2.1. Аукционнарга билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы буенча җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә (алга таба – Исемлек) кертелгән җир асты байлыклары кишәрлекләре чыгарыла.

2.2. Исемлек, Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлык белән килешү буенча, Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның 2012 елның 15 июнендәге 687 номерлы боерыгы белән расланган тәртиптә Министрлык тарафыннан расллана.

## 3. Аукцион комиссиясе

3.1. Аукцион комиссиясе Министрлык боерыгы белән төзелә. Аның составын үзгәртү Министрлык боерыгы белән Аукцион уздырыла башлаганчы өч көннән дә соңга калмыйча расллана.

Аукцион комиссиясе әгъзалары тарафыннан Аукцион комиссиясе компетенциясенә кертелгән карарларны кабул итү вәкаләтләрен аның башка әгъзаларына тапшыру рөхсәт ителми.

Министрлык тарафыннан Аукцион үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, җир асты байлыкларының һәр конкрет кишәрлеге яки җир асты байлыклары кишәрлекләренең бер төркеме буенча түбәндәгеләр расллана:

- Аукцион комиссиясенең составы;
- Аукционны үткәрү тәртибе һәм шартлары.

3.2. Аукцион комиссиясе эшчәнлеген оештыру максатларында Министрлык түбәндәгеләрне тәэмин итә:

- булачак Аукционнар турында игъланнар урнаштыруны;
- Аукционнар үткәрү шартларын һәм тәртибен эшләүне;
- үткәрелгән Аукционнар буенча документларны рәсмиләштерүне, комплектацияләү һәм җаваплы итеп саклауны;
- җир асты байлыкларының тиешле кишәрлегеннән файдалануга лицензия шартларын әзерләгәндә Аукцион шартларын гамәлгә ашыруны.

3.3. Комиссия әгъзалары тарафыннан Аукцион комиссиясе компетенциясенә кертелгән карарларны кабул итү вәкаләтләрен теләсә кайсы формада аның башка әгъзаларына тапшыру рөхсәт ителми.

3.4. Һәр Аукцион шартларында Аукцион комиссиясенең эш һәм карарлар кабул итү тәртибе билгеләнә.

3.5. Аукцион комиссиясе утырышлары, әгәр аларда расланган составның яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы була.

3.6. Һәр утырышта Аукцион комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзаланган беркетмә алып барыла.

3.7. Аукцион комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

3.8. Аукцион комиссиясе карарлары, әгәр алар өчен комиссия әгъзаларының исемлек составының кимендә яртысы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.10. Аукцион үткәрүнең йомгаклау беркетмәсе түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- Аукционга чыгарыла торган җир асты байлыклары кишәрлегенең атамасы;
- Аукцион комиссиясеннән катнаша торган әгъзалар исемлеге;
- Аукционда катнашуга кертелгән гариза бирүчеләр исемлеге;
- җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдаланган өчен бер тапкыр түләүнең башлангыч һәм ахыргы күләме;
- Аукционда җиңүченең тулы рәсми атамасы.

3.11. Аукцион комиссиясе әгъзалары, комиссия карары белән килешмичә, үткәрелгән Аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә аерым фикер кертә ала.

## 4. Аукцион шартларының эчтәлеге

4.1. Аукцион шартлары бер мәгънәдә аңлатылырга һәм җиңүчене ачыклау өчен объектив шартлар тудырырга тиеш.

4.2. Аукционның технологик, икътисадый, экологик һәм башка шартларын нигезләү өчен Аукцион шартларын эшләгәндә, Аукционда катнашу өчен алына торган җыемнар хисабына, түләүле нигездә Министрлык тарафыннан фәнни яки башка оешмалар, шулай ук бәйсез экспертлар җәлеп ителергә мөмкин.

4.3. Аукцион шартлары җир асты байлыкларыннан файдалану төренә, җир асты байлыклары кишәрлегенең яки җир асты байлыклары кишәрлекләре төркеменең өйрәнелгән дәрәҗәсенә һәм җир асты байлыклары турындагы законнар нигезендә башка факторларга бәйле рәвештә түбәндәгеләрне үз эченә:

- җир асты байлыклары кишәрлеге турында гомуми белешмәләр;
- җир асты байлыклары кишәрлегенең геологик характеристикасы;
- җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануның төп шартлары;
- Аукционда катнашу өчен гаризага карата таләпләр;
- Комиссиянең эш һәм карарлар кабул итү тәртибе;
- гариза бирүчеләрне Аукционда катнашуга кертү критерийлары;
- Аукционда җиңүчене билгеләү критерийлары;
- Аукционны гамәлдә түгел дип тану тәртибе һәм шартлары;
- Аукционда катнашу буенча чикләүләр;
- катнашучылар тарафыннан мәҗбүри һәм бер тапкыр түләү мәҗбүрилеге турында мәгълүмат;
- Аукцион нәтиҗәләре буенча якларда барлыкка килә торган үзара йөкләмәләр һәм җаваплылык турында кисәтү;
- Аукционны оештыру һәм үткәрү өчен кирәкле башка мәгълүмат.

4.4. Аукцион шартлары гариза бирүчеләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә Аукцион предметы булып торган эшләрне башкаручы затлар буларак үзләренә белдерелә торган таләпләргә туры килү-килмәве турындагы күрсәтмәне үз эченә алырга тиеш:

- гариза бирүченең штатында квалификацияле белгечләр булуы турында;

- гариза бирүченең күрсәтелгән җир асты байлыкларыннан файдалану төре буенча эшләрне нәтиҗәле һәм куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чаралары булуы турында.

4.5. Аукцион шартларында анда катнашучылар тарафыннан бер тапкыр түләү зарурлыгы турында мәгълүмат булырга тиеш, ул гариза бирүче тарафыннан бер тапкыр түләүнең билгеләнгән срокларда түләнүен һәм Аукцион шартларында билгеләнә торган күләмдә алдан акча түләнүен тәэмин итә торган банк гарантиясен үз эченә ала.

4.6. Аукцион шартларында гаризаларны кабул итә торган вәкаләтле орган, гаризаны кабул итү вакыты һәм урыны, Аукцион үткәрү вакыты һәм урыны, шулай ук түләүләрне күчерү өчен банк реквизитлары күрсәтелә.

4.7. Аукцион үткәрү турында белдерү түбәндәге мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алырга тиеш:

- Аукционны үткәрү формасы;
- Аукционны үткәрү датасы һәм вакыты;
- Аукционның предметы
- Аукцион адымы;
- Аукционда катнашу өчен гаризалар тапшыру датасы һәм вакыты;
- Аукционны оештыручы оешманың атамасы, урнашкан урыны, почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры һәм Аукционны оештыру өчен җаваплы затның урнашу урыны;
- Аукционда җиңүчене чикли яисә авырайта торган шартлар турында мәгълүмат.

4.8. Аукционнар үткәрү турында игъланнар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатулар уздырылуы турындагы мәгълүматны урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтын билгеләү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 10 сентябрендәге 909 номерлы карары нигезендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатулар уздырылуы турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (www.torgi.gov.ru) (алга таба – Рәсми сайт), шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында www.eco.tatarstan.ru (алга таба – Министрлык сайты) урнаштырыла.

Аукцион үткәрү турында белдерүдә, шул исәптән, әлеге боерыкның 1.3 пункты нигезендә расланган Аукционны үткәрү тәртибе һәм шартлары да була.

4.9. Аукцион үткәрү турында белдерү аны үткәрү көненә кадәр кимендә 45 көн алдан Рәсми сайтта урнаштырыла.

4.10. Аукцион, технологик, программа, лингвистик, хокукый һәм оештыру ягыннан тәэмин итү чараларын кулланып, электрон формада үткәрелергә мөмкин.

Аукционны электрон формада үткәрү өчен, Министрлык, оешу-хокук формасына, милекчелек формасына, капиталның урнашу урынына һәм килеп чыгу урынына бәйсез рәвештә, аны эшләтү өчен кирәкле программа-аппарат чараларына ия булган электрон мәйданчык хуҗасы булган юридик затны җәлеп итәргә һәм

Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон Аукционнар уздырылуын тәэмин итәргә хокуклы.

Министрлык «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тәртиптә, электрон Аукционны оештыру һәм үткәрү буенча аерым функцияләрне үтәү өчен, шул исәптән электрон мәйданчыкта да, электрон формада Аукцион уздырылуы турында Белдерү эшләү һәм Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру, электрон Аукционны уздыруны тәэмин итүгә бәйле башка функцияләрне башкару өчен дә, юридик затны (махсуслаштырылган оешманы) җәлеп итәргә хокуклы.

## 5. Аукционда катнашучылар

5.1. «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 9 статьясында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы алу өчен аукционда катнашуга гариза формасын раслау турында» 2012 елның 20 октябрендәге 876 номерлы карары (алга таба – ТР МК карары) белән расланган форма буенча, «Җир асты байлыклары турында» ТР Законының $35^2$ статьясында күрсәтелгән документларны теркәп, Министрлыкка гариза тапшырган дәгъва белдерүчеләр Аукционда катнашуга кертелә.

5.2. Дәгъва белдерүчеләрнең Аукционда катнашуы аларның җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануның төп шартларын тануы һәм аларны төп шартлар сыйфатында лицензиягә кертүгә ризалык бирүе дигәнне аңлата.

Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия алганнан соң, җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 22 статьясындагы 7 пункты нигезендә, лицензия бирелгәндәге шартлардан шактый аерыла торган шартлар барлыкка килгән очракта, аларны яңадан карау буенча лицензияне биргән органнарга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.3. Аукционны үткәргәндә җиңүчене ачыклауның төп критерие – җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы өчен бер тапкыр бирелә торган түләү күләме.

5.4. Субъектларның аерым категорияләре өчен федераль законнарда Аукционнарда катнашу буенча чикләүләр билгеләнә.

5.5. Аукционда катнашучыларның мәнфәгатьләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә Аукционда катнашучылар исеменнән эш итүгә хокуклы физик һәм юридик затлар яклый.

## 6. Аукционнарда катнашу өчен гаризалар

6.1. Аукционда катнашу өчен дәгъва белдерүче (алга таба – гариза бирүче) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган форма буенча гариза, шулай ук түбәндәге документларны тапшыра:

гариза бирүченең гамәлгә кую документларының күчермәләре (әгәр гариза бирүче булып юридик зат торса);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан) өземтә;

гариза бирүченең салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп;

салым һәм җыемнар түләү буенча бурычлар булуы яки булмавы турында салым органнарыннан белешмә;

гариза бирүченең һәм җир асты байлыклары участокларыннан файдалануга бәйле эшчәнлек төрләренә җәлеп ителә торган подрядчыларларның лицензияләре күчермәләре (булган очракт);

гариза бирүченең соңгы хисап датасына бухгалтерлык балансы күчермәсе, аны кабул итү турында салым органы тамгасы белән;

гариза бирү датасына кадәр бер ай эчендә гариза бирүче счетлары буенча акчалар әйләнеше турында банк оешмаларыннан белешмәләр;

кредит яки кредит килешүләре күчермәләре (булган очракта);

подряд килешүләренең күчермәләре (булган очракта);

кулланыла торган технологияләр турында белешмә, аларны тасвирлап, бораулау һәм тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чаралар исемлеге, аларның гариза бирүчегә яисә җәлеп ителә торган подрядчыга каравын дәлилләп;

гариза бирүченең яки җәлеп ителә торган подрядчыларның штат расписаниесе күчермәсе;

эшләрне башкарачак белгечләрнең квалификация дипломнары күчермәләре.

Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга яки оригиналлар күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

6.2. Аукционда катнашу өчен гаризалар кабул итүне тәмамлау вакыты Аукционны уздыру турында игълан беренче тапкыр басылып чыккан көннән алып кимендә 30 календарь көне булырга тиеш.

6.3. Аукционда катнашу өчен гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

а) теркәлә торган хат;

б) бер өлеше сыйфатында акча түләүне раслый торган документлар (Аукцион турындагы документларда күрсәтелгән сумманы күчерү турында банк тамгасы белән, түләү йөкләмәсенең оригиналы);

в) Аукционда катнашу өчн җыем сыйфатында акча түләүне раслый торган документлар (Аукцион турындагы документларда күрсәтелгән сумманы күчерү турында банк тамгасы белән, түләү йөкләмәсенең оригиналы).

6.4. Гариза, Аукционда катнашу өчен җыем, акчаның бер өлеше һәм гаризаны теркәү турындагы Килешү нигезендә старт түләвен гариза бирүче тарафыннан түләгәннән соң, тапшырылган дип санала.

6.5. Аукционда катнашу өчен гариза тапшырган гариза бирүче, Аукционда катнашу өчен гаризаларны карый башлаган көнгә һәм вакытка кадәр теләсә кайсы вакытта аны кире алырга хокуклы. Министрлык үз гаризасын кире алган, җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр кертелгән түләүне гариза бирүчегә Аукционда катнашу өчен гаризаны кире алу турында хәбәр алынганнан соң ун эш көне эчендә кире кайтара.

6.6. »Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 42 статьясы нигезендә, Аукционда катнашу өчен җыем суммасы Аукционга әзерләнү, аны уздыру һәм аңа йомгак ясау, җир асты байлыклары кишәрлеге турында мәгълүмат әзерләү, җәлеп ителә торган экспертларның хезмәте өчен түләү чыгымнарыннан чыгып билгеләнә.

6.7. Аукционда катнашу өчен гаризаларны карау срогы Аукционда катнашу өчен гаризалар бирелгән көннән соң 15 календарь көненнән дә артмаска тиеш.

6.8. Аукционда катнашу өчен гаризаны түбәндәге очракларда кабул итүдән баш тартыла:

1) гариза билгеләнгән таләпләрне бозып тапшырылган очракта, шул исәптән аның эчтәлеге Аукционның игълан ителгән шартларына туры килмәсә дә;

2) гариза бирүче аңлы рәвештә үзе турында дөрес булмаган белешмәләр тапшырганда;

3) гариза бирүче эшләрне нәтиҗәле һәм куркынычсыз уздыру өчен кирәкле финанс һәм техник чараларга, квалификацияле белгечләргә ия булуы яки ия булачагы турында дәлилләмәләр тапшырмаган очракта һәм тапшыра алмаса;

4) әлеге гариза бирүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгән очракта монополиягә каршы таләпләр үтәлмәсә.

6.9. Аукцион үткәргәндә законнардагы таләпләрнең, суд актлары нигезендә Аукцион үткәрүнең расланган тәртибен бозу очраклары ачыкланган очракта яисә җиңеп булмый торган шартлар нәтиҗәсендә, Аукцион комиссиясе утырышы көненә кадәр Министрлык тарафыннан Аукцион уздырылуын туктату турында карар кабул ителә.

## 7. Аукционнарны үткәрү процедурасы

7.1. Җир асты байлыкларыннан файдаланучыны аукцион системасында сайлаган вакытта Аукционда катнашуга гариза белән берлектә дәгъва белдерүчеләрнең Аукционның расланган шартларын (җир асты байлыкларыннан файдалануның төп шартларын) үтәү буенча язмача йөкләмәләре дә сорала.

7.2. Аукционда катнашу өчен затның вәкаләтләрен раслаучы документлар Аукцион үткәрү барышында тикшерелә.

7.3. »Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $13^1$ статьясы нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы өчен бер тапкыр түләүнең иң зур күләмен тәкъдим иткән катнашучы Аукционда җиңүче дип таныла.

7.4. Аукцион түбәндәге тәртиптә үткәрелә:

- теркәгәндә Аукционда катнашучыларга бирелгән теркәү номерлары язылган табличкалар бирелә, аларны катнашучылар, әлеге сумманы бирергә әзер булса, чираттагы түләү күләмен игълан иткәннән соң күтәрә;

- Аукцион бер тапкыр түләүнең старт күләмен игълан итүдән башлана, һәм Аукционда игълан ителгән һәр сумма Аукцион шартларында билгеләнгән Аукцион адымы зурлыгы белән билгеләнергә тиеш;

- әгәр бер тапкыр түләүнең башлангыч күләмен өч тапкыр игълан иткәннән соң, Аукционда катнашучыларның берсе дә үзенең теркәү номеры белән табличканы күтәрмәсә, кишәрлек буенча Аукцион хәл ителмәгән дип санала һәм объект Аукционнан төшерелә;

- әгәр бер тапкыр түләү күләмен өч тапкыр игълан иткәннән соң, катнашучыларның берсе дә үзенең теркәү номеры язылган табличканы күтәрмәсә, Аукцион тәмамлана һәм номеры соңгы тапкыр игълан ителгән катнашучы анда җиңүче дип таныла.

7.5. Аукцион үтмәгән дип таныла, әгәр дә:

- Аукционда катнашу өчен гаризалар булмаса;

- Аукционда катнашу өчен бер генә гариза теркәлгән булса;

- гариза бирүчеләрнең берсе дә Аукционда катнашуга кертелмәгән булса;

- Аукционда катнашуга бары тик бер генә гариза бирүче кертелгән булса;

- Аукцион комиссиясенең йомгаклау утырышында бары тик бер генә гариза бирүче катнашса яки гариза бирүчеләр катнашмаса;

- Аукционда катнашучылар тарафыннан старт күләменнән зуррак дәрәҗәдә бер тапкыр бирелә торган түләү тәкъдим ителмәсә;

- Аукционда җиңүче Аукцион нәтиҗәләре буенча йөкләмәләрне үтәүдән читләшсә;

- Аукционда җиңүче җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукыннан язма рәвештә баш тарту турында белдерсә;

- Аукцион үткәрү барышында әлеге Аукцион шартларын җитди бозылса.

7.6. Аукцион узмаган дип танылган очракта, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия бирелми.

Аукционны гамәлдә булмаган дип тану турында карар Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры боерыгы белән раслана.

Яңа Аукцион үткәрү турында белдерү әлеге Нигезләмәнең 4.7 һәм 4.8 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

7.7. Аукционда катнашу старт түләвенә тигез булган алдан акчаны түләп кую белән аңлатыла, ул җиңүчедән гайре, Аукцион шартларында билгеләнгән срок эчендә Аукциондагы барлык катнашучыларга да кире кайтарыла. Аукционда җиңүчегә алдан түләнгән акча кире кайтарылмый, ә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы өчен бер тапкыр түләгәндә исәпкә алына.

7.8. Әгәр Аукционда җиңүче проектны һәм җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турындагы лицензия килешүен алганнан соң 10 көн эчендә әлеге документларның имзаланган проектларын Министрлыкка тапшырмаса,

Министрлык җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында карарны юкка чыгару турында карар кабул итә.

Бу очракта, шулай ук Аукционда җиңүче файдалану хокукыннан баш тарткан очракта да, Аукционда җиңүче тарафыннан алдан кертелгән акча кире кайтарылмый.

## 8. Аукцион нәтиҗәләре буенча карарлар кабул итү

8.1. Аукцион нәтиҗәләре буенча Аукцион комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- Аукцион нәтиҗәләрен раслау һәм, җир асты байлыклары кишәрекләреннән файдалану хокукын биреп, әлеге Аукционда җиңүчеләрне тану турында;
- әлеге Нигезләмәнең 7.5 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча Аукционны узмаган дип тану турында;
- Аукционны үткәргәндә законнарны бозу (шул исәптән Аукцион шартларын бозу) ачыкланса, Аукционны үткәрүне туктату турында.

8.2. Аукцион нәтиҗәләрен раслау турындагы карар Аукцион үткәрү датасыннан соң 30 календарь көненнән артмаган срокта кабул ителә.

8.3. Министрлык, үз компетенциясе нигезендә, җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына Аукционнар шартларын әзерләү, аларны уздыру һәм Аукционнарның йомгаклары буенча карарлар кабул итүгә бәйле вәкаләтләрне гамәлгә ашыра, Аукцион нәтиҗәләрен раслау турында карар кабул ителгән көннән соң 30 календарь көне узганчы Министрлык сайтында мәгълүмат урнаштыра.

8.4. Аукцион нәтиҗәләре буенча җиңүчегә лицензия җир асты байлыклары турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә, лицензия биргән өчен бер тапкыр түләнә торган түләү калдыгын һәм дәүләт пошлинасын керткәннән соң бирелә.

8.5. Аукционда җиңүчегә лицензия бирү өчен аның тарафыннан өстәмә документлар тапшыру таләп ителми.

8.6. Лицензия бирүгә нигез булган беркетмә имзаланган көннән башлап ун календарь көне узмыйча Аукцион нәтиҗәләре буенча лицензия бирү рөхсәт ителми, ә мондый беркетмәне Министрлык сайтында урнаштыру каралган булса, мондый урнаштыру көненнән соң ун календарь көне узмыйча рөхсәт ителми.

## 9. Электрон формада Аукцион үткәрү үзенчәлекләре

9.1. Электрон мәйданчык операторының функцияләре:

- электрон мәйданчык регламентында билгеләнгән тәртип нигезендә электрон мәйданчыкның эшкә сәләтлелеген һәм эшләвен тәэмин итә;
- гариза бирүчене электрон мәйданчык регламенты нигезендә терки;
- электрон мәйданчыкта теркәлүне раслаганнан соң, гариза бирүчегә электрон формадагы Аукционда катнашу мөмкинлеген тәэмин итә;

- электрон култамга сертификатлары һәм вәкаләтләре нигезендә хокукы булган теркәлгән гариза бирүчеләргә электрон формадагы Аукционда катнашу процедурасын тәэмин итә;

- гариза бирүчеләрдән Аукционда катнашу өчен гаризаларны һәм аларга теркәп тапшырыла торган документларны кабул итә;

- Аукционда катнашу өчен гаризаларны, керүенә карап, теркәп бара;

- гариза бирүченең Аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачылган счеты буенча операцияләрне туктата һәм яңадан торгыза;

- Аукционда җиңүче дип танылган гариза бирүче счетыннан электрон формадагы Аукционда катнашкан өчен түләү сыйфатында әлеге Нигезләмәнең Аукцион документында билгеләнгән күләмдә акча күчерә.

9.2. Аукционда катнашу өчен гаризалар тапшыру тәртибе, урыны, тапшыра башлау датасы һәм тәмамлау датасы.

9.2.1. Аукционда катнашу өчен, Аукцион үткәрү өчен билгеләнгән электрон мәйданчыкта теркәлгән гариза бирүче, Аукцион турындагы документ таләпләре һәм электрон мәйданчык регламенты нигезендә, Аукционда катнашу өчен гариза тапшыра.

9.2.2. Аукционда катнашу өчен гариза электрон формада ТР МК карары белән билгеләнгән форма буенча тапшырыла.

9.2.3. Аукционда катнашу гариза бирүченең Аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр уздыру өчен ачылган счетында счет буена үзләренә карата операцияләр туктатылмаган акча күләме Аукцион турындагы документта каралган күләмдә булырга мөмкин.

9.2.4. Гариза бирүче Аукционда катнашу өчен гаризаны Аукцион үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән, Аукционда катнашу өчен гаризалар тапшыру вакытының теләсә кайсы чорында тапшырырга хокуклы.

9.2.5. Аукционда катнашу өчен гариза гариза бирүче тарафыннан электрон документлар формасында электрон мәйданчык операторына җибәрелә, аның составы Аукцион турындагы документта билгеләнә. Әлеге электрон документлар бер үк вакытта тапшырыла.

9.2.6. Аукционда катнашу өчен гариза килүе мондый гариза бирүченең электрон мәйданчыкта Аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр уздыру өчен ачылган счетында Аукционда катнашу өчен гаризаны тәэмин итәргә җитәрлек күләмдәге акча күләменә карата операцияләрне туктату турында йөкләмә булып тора.

9.2.7. Гариза бирүче тарафыннан Аукционда катнашу өчен гариза тапшыру аның гаризаны тәэмин итү сыйфатында Аукционда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр уздыру өчен ачылган счетындагы акчаларның алынуына ризалыгы булып тора.

9.2.8. Аукционда катнашу өчен гаризаны карый башлаган вакыттан башлап бер сәгать эчендә электрон мәйданчыкның операторы Аукционда катнашу өчен гариза тапшырган гариза бирүченең анда канашуын тәэмин итү буенча операцияләр уздыру счеты буенча Аукционда катнашу өчен гаризаны тәэмин итәрлек күләмдәге

акча чараларына карата операцияләрне туктата, аңа тәртип саны бирә һәм гариза бирүчегә җибәрелә торган электрон документ формасында раслый, тәртип номеры беркетелгән гаризаның алынуын тәэмин итә.

9.3. Аукционны электрон формада үткәрү тәртибе.

9.3.1. Электрон мәйданчыкта Аукцион Аукцион үткәрү турында игъланда күрсәтелгән көн һәм вакыт аралыгында үткәрелә.

9.3.2. Аукцион турындагы документларда билгеләнгән тәртиптә, белдерүдә күрсәтелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен башлангыч (минималь) бәяне арттыру юлы белән уздырыла.

9.3.3. Аукцион адымы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә башлангыч (минималь) бәядән 10 процент тәшкил итә.

9.3.4. Аукцион үткәргәндә Аукционда катнашучылар җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында Аукцион адымына тигез зурлыкта, агымдагы тәкъдимнәрне арттып җибәрүне күздә тоткан тәкъдимнәрен җиткерә.

9.3.5. Аукцион үткәргәндә Аукционда катнашучылар җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә элегрәк Аукционда катнашучы тарафыннан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен тәкъдим ителгән тәкъдим күләменә тигез яки аннан азрак булган, шулай ук җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен нульгә тигез булган бәя турында тәкъдим җиткерергә хокуклы түгел.

9.3.6. Аукцион үткәргәндә Аукционда катнашучылардан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында тәкъдимнәрне кабул итү вакыты электрон мәйданчык регламентында билгеләнә. Әлеге вакыт дәвамында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында катнашучыларның яңа тәкъдимнәре җиткерелмәсә, Аукцион тәмамланган дип санала.

9.3.7. Аукцион үткәрү беркетмәсе электрон мәйданчык операторы тарафыннан Аукцион тәмамланганнан соң утыз минут эчендә электрон мәйданчыкта урнаштырыла. Беркетмәдә электрон мәйданчык адресы, Аукцион датасы, башлану һәм тәмамлану вакыты, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен башлангыч (минималь) бәя, Аукционда катнашучылар ясаган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында барлык максималь тәкъдимнәр, Аукционда катнашу өчен гаризаларга бирелгән тәртип номерларын күрсәтеп, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында тиешле тәкъдимнәр ясаган Аукционда катнашучылар тарафыннан җиткерелгән, әлеге тәкъдимнәрне керү вакыты күрсәтелә.

9.3.8. Аукционны уздыра башлаганнан соң, электрон мәйданчык регламентында билгеләнгән вакыт дәвамында, Аукционда катнашучыларның берсе дә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында тәкъдим җиткермәсә, Аукцион узмаган дип танылa.

9.3.9. Электрон мәйданчык операторы Аукцион үткәрүнең өзлексезлеген, Аукцион үткәрү өчен файдаланыла торган программа һәм техник чараларның ышанычлылыгын, Аукционда катнашучыларның анда катнашуга тигез дәрәҗәдә үтеп керә алуын тәэмин итәргә бурычлы.

9.4. Аукционда катнашу өчен гаризаларны карау, Аукционда җиңүчене билгеләү.

9.4.1. Аукцион комиссиясе Аукционда катнашу өчен гаризаның Аукцион турындагы документлар таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында өч эш көне дәвамында карар кабул итә. Аукционда катнашу өчен әлеге гаризаларны карау Аукционда катнашучы тарафыннан тапшырылган, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен иң югары бәя тәкъдим иткән гаризадан башлана.

9.4.2. Үткәрү нәтиҗәләре буенча Аукцион үткәрүнең йомгаклау беркетмәсе төзелә, ул кул куелганнан соң өч эш көне дәвамында электрон мәйданчыкта урнаштырыла.

Беркетмәдә Аукционда катнашып, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен бәя турында тәкъдим ителгән максималь бәяләр кимүгә карап билгеләнгән затларның, гаризаларына беркетелгән тәртип номерларын күрсәтеп, Аукционда катнашучыларның исемнәре (атамалары) күрсәтелә, Аукционда җиңүче билгеләнә. Шулай ук Аукцион турындагы документ таләпләренә туры килми дип танылган Аукционда катнашучыларның исемнәре (атамалары) да, туры килмәү сәбәпләрен күрсәтеп, күрсәтелә.

Гаризалары Аукцион турындагы документларның таләпләренә туры килми дип танылган Аукционда катнашучылар Аукционнан төшеп калган дип танылa.

Аукцион турындагы документ таләпләренә туры килә торган, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен Аукционда катнашучылар арасыннан иң югары бәяне тәкъдим катнашучы Аукционда җиңүче дип танылa.

9.4.3. Аукционга йомгак ясау беркетмәсе электрон мәйданчыкта урнаштырылган көннән башлап бер эш көне дәвамында электрон мәйданчык операторы Аукцион турындагы документларның таләпләренә туры килми дип танылган Аукционда катнашучының Аукционнарда катнашуны тәэмин итү буенча операцияләр уздыру счеты буенча Аукционда катнашуга гаризаны тәэмин итәрлек күләмдәге акчаларга карата туктатылган операцияләрне торгыза.

9.4.4. Аукционда катнашучылар, Аукцион уздыруның йомгаклау беркетмәсе нигезендә Аукционда катнашу гаризасы беренче номер алган катнашучыдан тыш, әлеге беркетмә басылып чыгу вакытыннан башлап Аукционда катнашудан чыга. Шул ук вакытта электрон мәйданчык операторы Аукционда катнашу гаризасын тәэмин итәрлек күләмдәге акчага карата әлеге катнашучыларның Аукционнарда катнашуын тәэмин итү операцияләрен уздыру буенча счетында туктатылган операцияләрне торгыза.

9.4.5. Аукционны оештыручы Аукционга йомгак ясау беркетмәсе электрон мәйданчыкта урнаштырылган көннән башлап биш эш көне эчендә лицензия проектларын һәм лицензия килешүләрен әзерли, Аукционда җиңүче тәкъдим иткән максималь бәя нигезендә Аукционнар нәтиҗәләре буенча йөкләмәләр үтәлүне исәпкә алып, лицензия проектларын һәм лицензия килешүләрен электрон мәйданчык операторына җибәрә. Электрон мәйданчык операторы бер сәгать эчендә кергән документларны Аукционда җиңүчегә җибәрә.

9.4.6. Аукционда җиңүче лицензия проектын һәм лицензия килешүен алганнан соң 10 эш көне эчендә Аукционны оештыручыга имзаланган документларны тапшыра һәм Аукцион уздырылуы турындагы игъланда күрсәтелгән счетка аукцион нәтиҗәләре буенча йөкләмәләрне үтәлүен тәэмин итү суммасын күчерә һәм лицензия бирелгән өчен дәүләт пошлинасы түләнгәнлеген раслый торган документны тапшыра.

9.4.7. Аукционны оештыручы өч эш көне дәвамында Аукцион нәтиҗәләре буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү өчен түләнгәнлеген һәм Аукционда җиңүче тарафыннан лицензия беркетмәсенә һәм лицензия килешүенә кул куелуын раслый, электрон мәйданчык операторына тиешле белдерүне җибәрә һәм Аукционда җиңүчегә теркәлгән лицензиянең һәм лицензия килешүенең ике яктан да имзаланган бер нөсхәсен кире кайтара.

9.4.8. Аукцион нәтиҗәләре буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү өчен түләүне раслау турында белдерү килгән һәм Аукционда җиңүче белән лицензия проектын һәм лицензия килешүен имзалаган көннән башлап бер эш көне эчендә электрон мәйданчык операторы Аукционда катнашуны тәэмин итү өчен файдаланылуы туктатылган акчаларга карата Аукционда катнашучыларның барысының да Аукционда катнашуны тәэмин итү операцияләрен уздыру счеты буенча туктатылган операцияләрне торгыза. Шул ук вакытта электрон мәйданчык операторы Аукционда катнашып, җиңүче дип танылган затның мондый Аукционда катнашу өчен түләү сыйфатында электрон мәйданчык операторы билгеләгән күләмдә түләгән акчаларын Аукционда катнашуны тәэмин итү операцияләрен уздыру счетыннан ала.

9.4.9. Аукционда җиңүче, лицензия һәм лицензия килешүе проектларын алганнан соң Аукционны оештыручы счетына Аукцион нәтиҗәләре буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү суммасын 10 эш көне эчендә күчермәсә яки өч нөсхәдә имзаланган кәгазь документларны тапшырмаса, Аукцион нәтиҗәләре буенча йөкләмәләрне үтәүдән читләшкән дип таныла.

9.4.10. Аукционда җиңүче Аукцион нәтиҗәләре буенча йөкләмәләрне үтәүдән читләшкән очракта, Аукцион комиссиясе читләшкән көннән соңгы бер эш көне эчендә Аукционны узмаган дип тану турында карар кабул итә һәм Аукционны оештыру яңадан Аукцион предметын сатуларга куярга хокуклы.

9.4.11. Аукцион нәтиҗәләрен раслау турындагы карар Аукцион үткәрү датасыннан соң 30 календарь көненнән артмаган срокта кабул ителә.

9.4.12. Аукцион үткәрү барышында төзелгән беркетмәләр, Аукцион үткәрү документлары, Аукцион үткәрү документларына кертелгән үзгәрешләр һәм Аукцион үткәрү документларына аңлатмалар Аукционны оештыручы тарафыннан кимендә өч ел саклана.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2020 елның 13.04. 481-п номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар уздыруның бертөр тәртибе һәм шартлары

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Үткәрелә торган Аукционның максаты – әлеге Бертөр тәртиптә билгеләнгән шартлар нигезендә иң отышлы шартларда________________________
__________________________________________________________________
(җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану максаты, гомумтаралган файдалы казылма атамасы)

(кайда) ___________________________________________________________,
(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме)

тормышка ашырырга сәләтле җир асты байлыкларыннан файдаланучыны билгеләү.

1.2. Аукцион уздырганда җиңүчене ачыклау өчен төп критерий булып Аукционда катнашучыларның берсе тәкъдим иткән җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы өчен бер тапкыр бирелә торган түләүнең максималь күләме тора.

1.3. Аукционда җиңүчегә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы һәм ______________________________ ______________________
(гомумтаралган файдалы казылма исеме) (җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме)

________ еллык чорга _____________________максатында лицензия биреләчәк.

Җир асты байлыкларыннан файдалануның әлеге Бертөр тәртипнең 5 бүлегендә билгеләнгән шартлары Җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турындагы лицензия килешүенә кертелә, ул җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең аерылгысыз өлеше булып тора.

1.4. Җир асты байлыкларыннан чыгарылган гомумтаралган файдалы казылмалар җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның милегендә тора.

1.5. Чыгару максаты - _________________________________________.
(гомумтаралган файдалы казылма атамасы һәм нинди максатлар өчен чыгарыла)

1.6. Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану срогы лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан чыгып исәпләнә һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә озайтылырга мөмкин.

1.7. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының хокуклары һәм бурычлары җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан башлана.

## 2. Аукционда катнашучылар

2.1. Аукционда эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары, шул исәптән гади ширкәттә катнашучылар, чит ил гражданнары, юридик затлар катнаша ала, әгәр законнарда башкача билгеләнмәгән булса.

2.2. Аукционда катнашучылар җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга карата законнарда билгеләнә торган таләпләргә җавап бирергә, квалификацияле белгечләргә, җир асты байлыкларыннан файдаланугa бәйле эшләрне нәтиҗәле һәм куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чараларга ия булырга тиеш (әлеге Бертөр тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә).

2.3. Аукционда катнашучыларның мәнфәгатьләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә Аукционда катнашучылар исеменнән эш итүгә хокуклы физик һәм юридик затлар яклый ала.

## 3. Җир асты байлыклары кишәрлеге турында гомуми белешмәләр

3.1. Файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлеге (яисә ятма) Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының ____________ № ________ боерыгы белән Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән.

3.2. _______________________________________________________ урнашу урыны
(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме)

___________________________Татарстан Республикасы муниципаль районында
(муниципаль район атамасы)

__________________________________________________________________________.
(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең географик бәйләнеше китерелә)

3.3. Җир асты байлыклары кишәрлегенә геологик өйрәнү чорына геологик аерып чыгарылган урын статусы һәм, тау итеп аерып чыгаруның тәгаенләштерелгән чикләрен таныклый торган документларны теркәү көненнән башлап, тау итеп аерып чыгарылган урын статусы бирелә.

Файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлегенең контурлары планында түбәндәге географик координаталар белән почмаклы нокталар белән чикләнгән (WGS - 84):

| Җир асты байлыклары кишәрлегенең почмак нокта номеры | Төньяк киңлеге | | | Көнчыгыш озынлыгы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Градуслар | Минутлар | Секундлар | Градуслар | Минутлар | Секундлар |
| | | | | | | |

Җир асты байлыклары кишәрлегенең мәйданы ______ га тәшкил итә.

3.4. Тау бүлеп бирелгән чикләре ________________________________________
(гомумтаралган файдалы казылма атамасы)

запаслары расланганнан соң тәгаенләштерелә.
сәнәгать категорияләрендә, техник проект эшләнмәсендә, аңа карата
уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсе һәм тиешле килештерүләр алынганнан соң.

3.5. Җир асты байлыклары кишәрлегендә федераль, төбәк һәм җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләр юк.

3.6. ____________________________________________________________ уздыру
(җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану максаты һәм гомумтаралган файдалы казылма атамасы)

өчен җир асты байлыкларыннан файдаланучыга җир кишәрлеге бирү җир асты байлыклары кишәрлеге чикләрендә, әлеге эшләрне үткәрү проектларын раслаганнан соң, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## 4. Җир асты байлыклары кишәрлегенең геологик характеристикасы

4.1.________________________________________________________________.
(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең геологик тасвирламасы)

4.2.________________________________________________________________.
(минераль чималның кыскача сыйфат һәм технологик характеристикасы)

4.3.________________________________________________________________.
(җир асты байлыклары кишәрлегендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруның тау-геологик шартлары)

4.4.________________________________________________________________.
(җир асты байлыклары кишәрлегендә гомумтаралган файдалы казылма хәзинәләре (ресурслары)

____________________________________________________________________
категория запасларын күрсәтеп)

## 5. Лицензия кишәрлегеннән файдалануның төп шартлары

5.1. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының хокуклары:

а) лицензиядә билгеләнгән максатка туры килә торган эшкуарлык яки башка эшчәнлек рәвеше өчен үзенә бирелгән җир асты кишәрлегеннән файдалану;

б) законнарга каршы килми торган әлеге эшчәнлек рәвешләрен мөстәкыйль сайлау;

в) үз эшчәнлеге нәтиҗәләренннән, шул исәптән чыгарылган минераль чималдан, лицензия һәм гамәлдәге законнар нигезендә файдалану;

г) үзләренең тау чыгару һәм аның белән бәйле эшкәртү производстволары калдыкларыннан, әгәр лицензиядә башкасы әйтелмәгән булса, файдалану;

д) үзенә бүлеп бирелгән тау чикләрдә файдалы казылма ятмалары мәйданнары төзүне чикләү;

е) лицензия нигезендә бүлеп бирелгән тау чикләрендә үз акчалары хисабына җир асты байлыкларын табуга өстәмә рөхсәтләрсез разведка үткәрү;

ж) федераль законнарда каралган очракларда, лицензия шартларын яңадан карау буенча лицензия биргән Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына (алга таба – Министрлык) мөрәҗәгать итү.

5.2. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы ________________________

________________________________________________________________
(җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану максаты һәм гомумтаралган казылма атамасы)

лицензияле кишәрлектә түбәндәге шартларны үтәп гамәлгә ашырырга бурычлы:

5.2.1. Геологик разведка һәм чыгару эшләре вакыты буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучы түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

а) лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан алып, ____ айдан соңга калмыйча геологик йөкләмәгә туры китереп, лицензияле кишәрлектә геологик разведка эшләре проектын Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә әзерләү һәм килештерү. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләре «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 28 статьясы (алга таба - «Җир асты байлыклары турында» РФ Законы) нигезендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләре дәүләт исәбенә алынырга тиеш;

б) лицензияле кишәрлектә геологик эзләнү эшләрен үткәрү, ________________________________ запасларын исәпләп, геологик хисап төзү һәм
(гомумтаралган файдалы казылма атамасы)

___________________ запасларының дәүләт экспертизасына тапшыру.
(запаслар категориясе)

лицензияне дәүләт теркәвенә алган көннән башлап _________ ай узганчы билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка;

в) запасларга дәүләт экспертизасы үткәрелгәннән соң 2 айдан да соңга калмыйча, геологик разведка эшләре нәтиҗәләре турындагы геологик хисапны Татарстан Республикасы буенча геологик мәгълүматның территориаль фондына һәм Министрлыкның геологик мәгълүмат фондына тапшыру;

г) лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан алып ______ ай узганчы, лицензияле кишәрлекне эшкәртүнең техник проектын билгеләнгән тәртиптә әзерләү, килештерү һәм раслау;

д) бүлеп бирелгән тауның төгәл чикләрен билгели торган документларны рәсмиләштерү (характерлы сызымнар, почмак нокталары координаталары белән) һәм, лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан соң ______ ай узганчы, аларны аерылгысыз состав өлеше буларак лицензиягә кертү;

е) лицензияне дәүләт теркәвенә алганнан соң _____ ай узганчы, лицензияле кишәрлектә тау әзерләү эшләрен башлау;

ж) лицензияне дәүләт теркәвенә алу датасыннан соң ____ ай узганчы проект егәрлегенә чыгу;

з) ел саен, 5 февральгә кадәр, Россия Федерациясенең Статистика буенча дәүләт комитетының «Россия Табигать ресурслары министрлыгына файдалы казылма запасларын, геология-разведка эшләрен һәм аларны финанслауны, судан файдалануны һәм әйләнә-тирәлекне пычраткан өчен исәпләнгән түләүләрне

статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментлар раслау турында» 2000 елның 13 ноябрендәге 110 номерлы карары белән расланган 5-гр формасы буенча статистика хисаплылыгын һәм җир асты байлыкларыннан файдалану барышында алына торган, файдалы казылмаларның запасларының торышы һәм үзгәрүе турында төгәл мәгълүматларны үз эченә алган башка геологик мәгълүматларны, шулай ук файдалы казылма запасларының үзгәрүен нигезли торган, тау күзәтчелеге органы белән килештерелгән материалларны аларга теркәп, аңлатма язуларын, шул исәптән файдалы казылмаларның хәзерге торышы һәм аларның күләме үзгәрүе турында маркшейдер хисабын Министрлыкка, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсенә (Ростехнадзор), «Идел буе федераль округы буенча геологик мәгълүмат территориаль фонды» федераль бюджет учреждениесенең Татарстан филиалына, «Россия федераль геология фонды» федераль дәүләт унитар фәнни-җитештерү предприятиесенә тапшыру;

и) разведкаланган, чыгарыла торган һәм җир астында калдырыла торган файдалы казылма запаслары, аларда булган компонентлар турында, файдалы казылмаларны алуга бәйле булмаган максатларда җир асты байлыкларыннан файдалану турында төгәл мәгълүматларны дәүләт статистикасы органнарына тапшыру.

5.2.2. Файдалы казылмалардан рациональ файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында җир асты байлыкларыннан файдаланучы түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

а) җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә законнарны, нормаларны һәм кагыйдәләрне үтәргә;

б) файдалы казылма байлыкларыннан файдалы казылмаларны тулсынча чыгару, аларны чыгарганда җир асты байлыкларының пычрануына юл куймау, лицензияле кишәрлекне файдалы казылманың сыйфатын һәм лицензияле кишәрлекнең сәнәгый кыйммәтен киметүче яисә аны эшләүне катлауландыра торган факторлардан саклау;

в) җир асты байлыкларында табыла торган һәм калдырыла торган файдалы казылма запасларының һәм алар белән бергә ятучы файдалы казылмаларның һәм файдалы казылмалар ятмаларын эшкәрткәндә юлдаш компонентларның маркшейдер эшләрен башкару күрсәтмәсендәге һәм җир асты байлыкларын саклау кагыйдәләрендәге таләпләр нигезендә исәпкә алырга;

г) җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны булдырмау яисә киметү өчен кирәкле чараларны күрергә;

д) җир асты байлыкларыннан рациональ файдалану һәм аларны саклау, җир асты байлыкларыннан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау белән бәйле эшләрне куркынычсыз алып бару таләпләрен үтәргә;

е) файдалы казылмалар чыгаруны бары тик бүлеп бирелгән тау чикләрендә генә алып бару;

ж) җир асты байлыкларыннан файдаланучының проект документлары составында расланган нормативлардан артып киткән файдалы казылмаларны югалту нормативларын Министрлык белән килештереп, үз вакытында расларга;

з) җир асты байлыкларыннан файдаланучының проект документлары составында расланган нормативлардан артмаган файдалы казылмаларны югалту нормативларын ел саен расларга;

и) билгеләнгән тәртиптә килештерелгән проект документлары нигезендә ятманы эшкәртергә;

к) җир асты байлыкларыннан файдалануның барлык төрләре процессында геологик, маркшейдер һәм башка документларны алып барырга;

л) җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр башкарылган урында рөхсәт документларының (кушымталары белән берлектә, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия, топографик планы белән берлектә тау бүлеп бирү акты, агымдагы чорга билгеләнгән тәртиптә килештерелгән тау эшләрен үстерү планы, җир кишәрлеген сәнәгать җирләре категориясенә күчерү турында карар (җир кишәрлекләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану очраклары өчен), Росрыболовство территориаль органы рөхсәте (су объектларында җир асты байлыкларыннан файдалану очраклары өчен) һ.б.) күчермәләрен булдырырга һәм контрольдә тотучы органнарга, аларның компетенциясенә туры китереп, аны күрсәтергә;

м) тау эшләрен үстерү буенча техник проектлар, планнар һәм схемалар таләпләрен үтәргә, нормадан тыш югалтуларны булдырмаска, файдалы казылмаларның сыйфатын киметмәскә һәм файдалы казылмаларны сайланма рәвештә генә эшкәртмәскә;

н) ятманы эшкәрткәндә запасларны вакытында ачарга, туфрак-үсемлекләр катламын һәм токымнарны аерым тупларга;

о) җир асты байлыкларыннан файдаланганда сирәк очрый торган палеонтология, археология һәм башка объектларны ачыклаганда, Министрлыкка хәбәр итәргә;

б) контрольлек итүче органнарның күрсәтмәләрен үтәргә.

Җир кишәрлекләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану очраклары өчен әлеге пунктның а-п пунктчаларына өстәмә рәвештә җир асты байлыкларыннан файдаланучының түбәндәге бурычлары кертелә:

- федераль законнарда башкача билгеләнмәгән булса, тиешле категорияле («сәнәгать җирләре») җирләрдә файдалы казылмалар чыгару эшләрен алып бару;
- җир асты байлыкларыннан файдаланганда бозылган җир кишәрлекләрен һәм башка табигать объектларын киләчәктә файдалану өчен яраклы хәлгә китерү;
- файдалы казылма ятмалары мәйданнарында үзирекле төзелешләрне кисәтү һәм әлеге мәйданнарны башка максатларда куллану тәртибен үтәү.

Су объектларында җир асты байлыкларыннан файдалану очраклары өчен әлеге пунктның а-п пунктчаларына өстәмә рәвештә җир асты байлыкларыннан файдаланучының түбәндәге бурычлары кертелә:

- ел саен, навигация чоры башланганчы, эшләр башкаруга Росрыболовство территориаль органыннан рөхсәт (килештерү) алу;
- гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен лицензия хуҗасы тарафыннан кулланыла торган эчке елга һәм катнаш («елга-диңгез») йөзү

судноларын ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS спутник навигациясе аппаратурасы ярдәмендә «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру;

- билгеләнгән тәртиптә расланган таксалар һәм методикалар нигезендә су биоресурсларына китерелгән зыян күләмен исәпләү һәм законнарда каралган тәртиптә аның өчен түләү.

5.2.3. Хезмәтне саклау һәм индустриаль куркынычсызлык максатларында җир асты байлыкларыннан файдаланучы түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

а) җәлеп ителә торган хезмәткәрләрнең һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрнең йогынтысы зонасында яшәүче халыкның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркынычсызлык;

б) куркыныч җитештерү объектларын үз вакытында проектлау, аларны декларацияләү, гамәлдәге законнарда каралган очракларда һәм тәртиптә сәнәгать куркынычсызлыгына экспертиза ясау;

в) лицензияләнә торган эшчәнлек төрләренә лицензияләр булдыру;

г) подрядчылар сыйфатында җәлеп ителә торган юридик һәм физик затларда җир асты байлыкларыннан файдалану буенча эшчәнлекне башкаруга дәүләт лицензиясе (таныклыгы, дипломы) белән расланган махсус квалификация һәм тәҗрибә булуны контрольдә тоту;

д) хәвефле җитештерү объектларын законнарда билгеләнгән очракларда дәүләт реестрында теркәү;

е) хәвефле җитештерү объектындагы авария очрагында башка затларның тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян китергән һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китергән өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә гражданлык җаваплылыгын иминиятләштерү;

ж) предприятиедә сәнәгать куркынычсызлыгы торышын, җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз алып бару буенча законнар, нормалар, кагыйдәләр, техник регламентлар таләпләрен үтәүгә производство контроле;

з) хәвефле җитештерү объекты персоналы өчен сәнәгый куркынычсызлык һәм хезмәтне саклау буенча күрсәтмәләр эшләү һәм раслау;

и) барлык хезмәткәрләр тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшләрне куркынычсыз алып бару кагыйдәләре таләпләрен үтәү;

к) тау эшләнмәләрен куркынычсыз хәлгә китерү һәм аларны консервацияләү буенча чаралар күрү, шулай ук нигезле очракларда, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору яисә туктаткан очракларда, шулай ук аның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң аларны юкка чыгару;

л) компетенцияләренә туры китереп чаралар уздыру өчен, эшләрне башкару урыннарына вәкаләтле дәүләт күзәтчелеге органнары вәкилләренә законнар нигезендә каршылыксыз үтеп керү мөмкинлеген тудыру;

м) кыйммәтле һәм куркыныч йөкләрнең, геологик, маркшейдер һәм башка документларның, махсус корреспонденциянең, шулай ук дәүләт серенә кертелгән белешмәләрне йөртүче йөкләрнең сакланышы;

н) әйләнә-тирә мохитне пычратуга бәйле барлык аварияләр турында Министрлыкка һәм башка вәкаләтле органнарга оператив хәбәр итү;

о) файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлеге чикләрендә урнашкан тау эшкәртмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларның куркынычсызлыгы.

5.2.5. Юридик һәм (яки) почта адресын үзгәртү турында Министрлыкка 10 көнлек срокта хәбәр итәргә.

5.3. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат елына уртача

______________________________________________________
(гомумтаралган файдалы казылмаларның һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме)

_______ мең куб.м (мең т) күләмендә чыгаруны тәэмин итәргә тиеш. Табу күләме һәм тау эшләренең юнәлеше билгеләнгән тәртиптә эшкәртмәнең техник проектында билгеләнә.

5.4. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат әлеге Бертөр тәртипнең 6.2, 6.3 һәм 6.4 пунктларында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләү һәм лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләргә тиеш.

5.5. Җир асты байлыкларыннан файдаланганда җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат әлеге Бертөр тәртипнең 6.5 - 6.6 пунктларында каралган түләүләрне кертә һәм салымнар түли.

5.6. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы лицензияле кишәрлектән файдалану шартларын үтәмәгән очракта, әлеге Бертөр тәртипнең 5.2.1 пунктындагы «г» пунктчасында һәм 5.4 пунктында күрсәтелгән очракта лицензияле кишәрлектән файдалану хокукы «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 20 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә туктатыла.

5.7. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат әлеге Бертөр тәртипнең 5.2.1 пунктында («г» пунктчасыннан тыш), 5.2.2, 5.2.3 һәм 5.5 пунктларында күрсәтелгән шартларны үтәмәгән очракта, лицензияле кишәрлектән файдалану хокукы «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 20 статьясындагы 2 өлешендә, 21 һәм 23 статьяларында билгеләнгән тәртиптә вакытыннан алда туктатылырга, туктатып торылырга яисә чикләнергә мөмкин.

5.8. Әлеге Бертөр тәртипнең 5.2-5.7 пунктларында күрсәтелгән төп шартлар лицензиягә һәм аның аерылгысыз состав өлешләренә кертелергә тиеш. Әлеге шартларны үзгәртү федераль законнарда билгеләнгән очракларда гына рөхсәт ителә.

5.9. Дәгъва белдерүчеләрнең Аукционда катнашуы алар тарафыннан лицензияле кишәрлектән файдалануның чын төп шартларын тану һәм аларны лицензиягә һәм төп шартлар сыйфатында аның аерылгысыз состав өлешләренә кертүгә ризалыгын аңлата.

5.10. Җир асты байлыклары һәм алардан файдалану турында мәгълүмат.

5.10.1. Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат башка федераль законнар белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең тиешле органнарына, Татарстан Республикасы җир асты

байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органына тапшырылырга, шулай ук дәүләт хакимиятенең күрсәтелгән органнары карамагында булган оешмаларга тапшырылырга тиеш.

Әлеге мәгълүматны куллану тәртибе һәм шартлары законнар нигезендә Татарстан Республикасының җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан билгеләнә.

5.10.2. Җир асты байлыкларыннан файдаланучының үз акчалары хисабына алынган геологик һәм башка мәгълүмат җир асты байлыкларыннан файдаланучының милке булып тора һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органының аны саклауны һәм системалаштыруны гамәлгә ашыручы геологик мәгълүмат фондына тапшырыла.

5.10.3. Җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат җир асты байлыклары турында беренчел геологик мәгълүматка һәм җир асты байлыклары турында интерпретацияләнгән геологик мәгълүматка бүленә.

Җир асты байлыклары турында башлангыч геологик мәгълүматка ия булган җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат аны куллану шартларын, шул исәптән коммерция максатларында да, күрсәтелгән геологик мәгълүматны Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органына тапшырганнан соң өч ел эчендә билгеләргә хокуклы.

Җир асты байлыклары турында интерпретацияләнгән геологик мәгълүматка ия булган җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат аны куллану шартларын, шул исәптән коммерция максатларында да, әлеге геологик мәгълүматны Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органына тапшырганнан соң биш ел эчендә билгеләргә хокуклы.

5.10.4. Законда билгеләнгән очракларда җир асты байлыклары турындагы геологик мәгълүмат, җир асты байлыкларыннан файдаланучының ризалыгын алмыйча, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, дәүләт хакимиятенең күрсәтелгән органнары карамагындагы оешмалар тарафыннан кулланылырга мөмкин.

Әлеге Бертөр тәртипнең 5.10.3 пунктында күрсәтелгән сроклар үткәннән соң, Татарстан Республикасы хокук иясе хокукына ия була. Шул ук вакытта җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат җир асты байлыклары турындагы законда тыелмаган теләсә нинди ысуллар белән үз акчалары хисабына алынган геологик мәгълүматтан файдаланырга хокуклы.

5.10.5. Җир асты байлыклары турындагы геологик һәм башка мәгълүматка милек хокукы башка милек объектлары өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә саклана.

5.10.6. Лицензиянең гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң, шул исәптән аның гамәлдә булуы срогыннан алда туктатылганда, җир асты байлыкларыннан файдаланучы, эшләрне тәмамлау мизгеленә тулыланган җир асты байлыклары кишәрлеге буенча барлык геологик, топогеодезия һәм маркшейдер документларын Министрлыкка саклау өчен тапшыра.

## 6. Түләүләр һәм җыемнар

6.1. «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 42 статьясы нигезендә җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы билгеләгән тәртип нигезендә Аукционда катнашкан өчен җыем күләме _____________ сум тәшкил итә һәм гариза бирүче счетына барлык катнашучылар тарафыннан күчерелә.

Аукционда катнашу өчен җыем анда катнашучыларга кире кайтарылмый.

6.2. Аукционда катнашучыларның барысы да гаризалар биргәнчегә кадәр алдан түләү килешүе нигезендә бер тапкыр түләнә торган түләү күләмен түли.

6.3. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләнә торган түләүнең старт күләме (җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын алу өчен бер тапкыр түләү) ____ сум күләмдә билгеләнә, ә Аукцион адымы – шуның 10%ы.

Аукцион үткәргәндә Аукционда катнашучылар җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында Аукцион адымына тигез зурлыкта, агымдагы тәкъдимнәрне арттып җибәрүне күздә тоткан тәкъдимнәрен җиткерә.

Аукцион нәтиҗәләре буенча билгеләнә торган җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләү калдыгы (алдан түләнгән сумманы тотып калган өчен гариза бирүче тарафыннан тәкъдим ителгән бер тапкыр түләү суммасы) Аукционда җиңүче тарафыннан, әлеге Бертөр тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә, реквизитлар буенча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә лицензия килешүе проектын җибәргән көннән алып 10 календарь көне эчендә кертелә.

6.4. Лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасы җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, әлеге Бертөр тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә реквизитлар буенча 7 500 (җиде мең биш йөз) сум күләмендә кертелә.

6.5. Җир асты байлыкларыннан файдаланганда җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләүләр һәм файдалы казылмалар чыгаруга салым түли, аларның ставкасы Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

6.5. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка салымнарны һәм җыемнарны түли.

## 7. Аукционда катнашу өчен гаризалар тапшыру һәм аларны карау тәртибе

7.1. Аукцион ______________________________________ үткәрелә.
(Аукционны үткәрү датасы һәм вакыты)

Аукцион уздырылуы турындагы мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сатулар уздырылуы турындагы мәгълүматны урнаштыру өчен Россия Федерациясе рәсми сайтында www.torgi.gov.ru, Министрлыкның рәсми сайтында www.eco.tatarstan.ru урнаштырыла (Аукцион электрон формада www.sale.zakazrf.ru сайтында уздырылган очракта).

Белешмәләр өчен телефон: (843) 267-68-47.

7.2. Аукционда катнашу өчен гариза бирүче вәкаләтле органга түбәндәгеләрне тапшыра:

1) Форма нигезендә Аукционда катнашу өчен тапшырылган документларның исемлеге (әлеге Бертөр тәртипкә 1 нче кушымта);

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы алу өчен аукционда катнашуга гариза формасын раслау турында» 2012 елның 20 октябрендәге 876 номерлы карары белән расланган форма нигезендә Аукционда катнашуга гариза.

3) Җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына әлеге Бертөр тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә гариза бирүче турында белешмәләр исемлеге.

Махсус формалары билгеләнгән документлар әлеге формалар нигезендә төзелергә тиеш.

Гаризага теркәп тапшырыла торган документлар һәм документлар исемлеге ябыштырылган конвертта кабул ителә (электрон формада Аукцион үткәрелгәндә документлар pdf форматындагы сканер аша чыгартылган аналогик документлар тапшырыла);

4) Ирекле формада төзелгән, теркәлә торган хат.

7.3. Аукционда катнашу өчен гаризалар кабул итү тәмамлану вакыты Аукционны уздыру турында игълан беренче тапкыр басылып чыккан көннән алып кимендә 30 календарь көне булырга тиеш.

Әлеге Бертөр тәртипнең 7.2 пунктында күрсәтелгән, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы буенча документлар Аукционда катнашу өчен гаризалар кабул итү көнендә (Мәскәү вакыты белән) 16.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Әлеге вакыттан соң тапшырылган гаризалар карауга кабул ителми.

## 8. Аукционны үткәрү тәртибе

8.1. Аукцион ______________________________________________ үткәрелә.
(Аукционны үткәрү формасы)

8.2. Аукцион белдерүдә күрсәтелгән көндә һәм вакытта үткәрелә.

8.3. Аукцион турындагы документларда билгеләнгән тәртиптә, Аукцион уздырылуы турындагы белдерүдә күрсәтелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен башлангыч (минималь) бәяне арттыру юлы белән уздырыла.

8.4. Аукцион адымының зурлыгы җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен беренче тапкыр түләү күләменең 10%ы күләмендә билгеләнә, аның күләме ___________ сум тәшкил итә.

8.5. Аукцион үткәргәндә Аукционда катнашучылар җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында Аукцион адымына тигез зурлыкта, агымдагы тәкъдимнәрне арттып җибәрүне күздә тоткан тәкъдимнәрен җиткерә.

8.6. Аукцион үткәргәндә Аукционда катнашучылар, түбәндәге таләпләрне исәпкә алып, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында тәкъдимнәр җиткерә:

- Аукционда катнашучы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында элегрәк Аукционда шундый катнашучы тарафыннан җиткерелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен бәя турындагы тәкъдимгә тигез яки аннан азрак булган тәкъдимне җиткерергә хокуклы түгел.

8.7. Катнашучылардан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында яңа тәкъдимнәр килмәгән очракта, Аукцион тәмамланган дип санала.

8.8. Аукционны үткәрү беркетмәсе Аукцион тәмамланганнан соң урнаштырыла. Беркетмәдә Аукционның датасы, аның башлану һәм тәмамлану вакыты, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен башлангыч (минималь) бәя, Аукционда катнашучылар ясаган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында барлык максималь тәкъдимнәр, Аукционда катнашу өчен гаризаларга бирелгән тәртип номерларын күрсәтеп, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә бәя турында Аукционда катнашучылар тарафыннан җиткерелгән тиешле тәкъдимнәр күрсәтелә.

8.9. Аукционны үткәрә башлагач Аукционда катнашучыларның берсе генә булса да бер тапкыр түләнә торган старт түләвенең бәясе турында тәкъдим җиткермәсә, Аукцион узмаган дип танула.

## 9. Аукционда катнашу өчен гаризаларны карау, Аукционда җиңүчене билгеләү

9.1. Аукцион комиссиясе Аукционда катнашу өчен гаризаның Аукцион турындагы документлар таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында карар кабул итә.

9.2. »Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 14 статьясы нигезендә җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына Аукционда катнашу өчен гаризаны кабул итүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:

1) гариза билгеләнгән таләпләрне бозып тапшырылган очракта, шул исәптән аның эчтәлеге Аукционның игълан ителгән шартларына туры килмәсә дә;

2) гариза бирүче аңлы рәвештә үзе турында дөрес булмаган белешмәләр тапшырганда;

3) гариза бирүче эшләрне нәтиҗәле һәм куркынычсыз уздыру өчен кирәкле финанс һәм техник чараларга, квалификацияле белгечләргә ия булуы яки ия булачагы турында дәлилләмәләр тапшырмаган очракта һәм тапшыра алмаса;

4) әлеге гариза бирүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгән очракта монополиягә каршы таләпләр үтәлмәсә.

Гариза бирүчегә аукционда катнашу өчен гариза кабул итүдән баш тарту нигезләренең әлеге исемлеге төгәл булып тора.

9.3. Үткәрү нәтиҗәләре буенча Аукцион үткәрүнең йомгаклау беркетмәсе төзелә, ул кул куелган вакыттан башлап бер көн эчендә ________________________
(урнаштыру урыны күрсәтелә)

урнаштырыла.

Беркетмәдә Аукционда катнашып, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен бәя турында тәкъдим ителгән максималь бәяләр кимүгә карап билгеләнгән затларның, гаризаларына беркетелгән тәртип номерларын күрсәтеп, Аукционда катнашучыларның исемнәре (атамалары) күрсәтелә, Аукционда җиңүче билгеләнә. Шулай ук Аукцион турындагы документ таләпләренә туры килми дип танылган Аукционда катнашучыларның исемнәре (атамалары) да, туры килмәү сәбәпләрен күрсәтеп, күрсәтелә.

Гаризалары Аукцион турындагы документларның таләпләренә туры килми дип танылган Аукционда катнашучылар Аукционнан төшеп калган дип таныла.

Аукцион турындагы документ таләпләренә туры килә торган, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге өчен Аукционда катнашучылар арасыннан иң югары бәяне тәкъдим катнашучы Аукционда җиңүче дип таныла.

## 10. Аукцион комиссиясенең эш тәртибе

10.1. Аукцион комиссиясе Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы боерыгы белән төзелә. Аның составын үзгәртү Министрлык боерыгы белән аукцион уздырыла башлаганчы өч көннән дә соңга калмыйча раслана. Аукцион комиссиясе әгъзалары тарафыннан Аукцион комиссиясе компетенциясенә кертелгән карарларны кабул итү буенча вәкаләтләрне аның башка әгъзаларына тапшыру рөхсәт ителми.

10.2. Аукцион комиссиясе вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- Аукционда катнашу өчен теркәп тапшырыла торган документлар белән гаризаларны карау;

- Аукционда катнашу өчен гаризаның Аукцион турындагы документлар таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында карар кабул итү.

- Аукционга йомгак ясау һәм җиңүчене билгеләү;

- Комиссия утырышлары беркетмәләрен төзи һәм имзалый;

- Аукцион үткәрү өчен кирәкле башка функцияләрне башкару.

10.3. Аукцион комиссиясе утырышлары, әгәр аларда аның исемлек составының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы була. Аукцион комиссиясенең һәр утырышында комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган беркетмә алып барыла.

10.4. Аукцион комиссиясе карарлары, шул исәптән Аукцион нәтиҗәләрен раслау турында да, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының кимендә яртысы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

10.5. Карар кабул иткәндә Аукцион комиссиясе әгъзасы тавыш бирүдән тыелып калырга хокуклы түгел.

10.6. Аукцион комиссиясе әгъзалары, комиссия карары белән килешмичә, үткәрелгән Аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә аерым фикер кертә ала.

## 11. Аукционны узмаган дип тану

11.1. Аукцион үтмәгән дип таныла, әгәр дә:

- Аукционда катнашу өчен гаризалар булмаса;
- Аукционда катнашу өчен бер генә гариза теркәлгән булса;
- гариза бирүчеләрнең берсе дә Аукционда катнашуга кертелмәгән булса;
- Аукционда катнашуга бары тик бер генә гариза бирүче кертелгән булса;
- Аукцион комиссиясенең йомгаклау утырышында бары тик бер генә гариза бирүче катнашса яки гариза бирүчеләр катнашмаса;
- Аукционда катнашучылар тарафыннан старт күләменнән зуррак дәрәҗәдә бер тапкыр бирелә торган түләү тәкъдим ителмәсә;
- Аукционда җиңүче Аукцион нәтиҗәләре буенча йөкләмәләрне үтәүдән читләшсә;
- Аукционда җиңүче җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукыннан язма рәвештә баш тарту турында белдерсә;
- Аукцион үткәрү барышында әлеге Аукцион шартларын җитди бозылса.

11.2. Аукцион узмаган дип танылган очракта, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия бирелми.

11.3. Аукционны гамәлдә булмаган дип тану турында карар Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры боерыгы белән раслана.

11.4. Аукцион үткәргәндә законнардагы таләпләрнең, суд актлары нигезендә Аукцион үткәрүнең расланган тәртибен бозу очраклары ачыкланган очракта яисә җиңеп булмый торган шартлар нәтиҗәсендә, Аукцион комиссиясе утырышы көненә кадәр Министрлык тарафыннан Аукцион уздырылуын туктату турында карар кабул ителә.

## 12. Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия бирү

12.1. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензияне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм Аукционда җиңүчегә тапшыру Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, үзгәртеп рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибен раслау турында» 2009 елның 12 октябрендәге 715 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, үзгәртеп рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

12.2. Әгәр Аукционда җиңүче җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукыннан язма рәвештә баш тартуы турында белдерсә, Министрлык Аукционны узмаган дип тану турында карар кабул итә. Шул ук вакытта Аукционда җиңүчесе тарафыннан алдан түләнгән акча кире кайтарылмый.

12.3. Җир асты байлыкларынан файдалануга лицензия бирүгә нигез булган беркетмә имзаланган көннән башлап ун көн узмыйча Аукцион нәтиҗәләре буенча лицензия бирү рөхсәт ителми, ә мондый беркетмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта урнаштыру каралган булса, мондый урнаштыру көненнән соң ун көн узмыйча рөхсәт ителми.

12.4. Аукционның әлеге шартларында бәян ителгән, лицензияле кишәрлектән файдалануда үтәү өчен мәҗбүри булган төп шартлар лицензиягә һәм аның аерылгысыз состав өлешләренә алдан килештерелгән буларак кертелә.

## 13. Белешмәләр өчен адреслар, телефоннар

Аукционда катнашуга бәйле барлык материаллар 420049, Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75 йорт, 311 кабинет адресы буенча җибәрелә, тел.: (843) 267-68-47, факс: (843) 264-53-19.

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар уздыруның бертөр тәртибе һәм шартларына 1 нче кушымта

Аукционда катнашу өчен тапшырыла торган документларның исемлек формасы

Аукционда катнашу өчен бирелгән документлар исемлеге

Әлегесе белән

_______________________________________________________________________________
(гариза бирүченең атамасы)

максатында (җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану максаты күрсәтелә) (гомумтаралган файдалы казылма атамасы күрсәтелә) Татарстан Республикасы муниципаль районында (муниципаль районның исеме) җир асты байлыклары кишәрлегеннән (җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең атамасы) файдалану хокукына Аукционда катнашу өчен түбәндә санап үтелгән документлар җибәрелгәнлеген раслый.

| т/с | Документның исеме (форма №) | Битләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Фамилия, исем, ата исеме һәм имза
Гариза бирүченең вәкаләтле заты ________________ ____________________
Кул кую датасы

Мөһер (булган очракта)

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар уздыруның бертөр тәртибе һәм шартларына 2 нче кушымта

Гариза бирүче турында мәгълүматлар исемлеге

Түбәндәгедән файдалану хокукына Аукционда катнашу өчен

______________________________________________________________
(җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме)

Татарстан Республикасының ______________________________________
__________________________________________муниципаль районында,
(муниципаль район атамасы)

________________________________________________________ максатында
(җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану максаты һәм гомумтаралган файдалы казылма атамасы)

гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

гариза бирүченең гамәлгә кую документларының күчермәләре (әгәр гариза бирүче булып юридик зат торса);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан) өземтә;

гариза бирүченең салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп;

салым һәм җыемнар түләү буенча бурычлар булуы яки булмавы турында салым органнарыннан белешмә;

гариза бирүченең соңгы хисап датасына бухгалтерлык балансы күчермәсе, аны кабул итү турында салым органы тамгасы белән;

Аукционда катнашуга гариза бирү датасына кадәр бер ай эчендә гариза бирүче счетлары буенча акчалар әйләнеше турында банк оешмаларыннан белешмәләр;

кредит яки кредит килешүләре күчермәләре (булган очракта);

подряд килешүләренең күчермәләре (булган очракта);

кулланыла торган технологияләр турында белешмә, аларны тасвирлап, бораулау һәм тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чаралар исемлеге, аларның гариза бирүчегә яисә җәлеп ителә торган подрядчыга каравын дәлилләп;

гариза бирүченең яки җәлеп ителә торган подрядчыларның штат расписаниесе күчермәсе;

эшләрне башкарачак белгечләрнең квалификация дипломнары күчермәләре.

Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә таныкланырга яки оригиналлар күрсәтеп тапшырылырга тиеш.

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар уздыруның бертөр тәртибе һәм шартларына 3 нче кушымта

Лицензияләүгә бәйле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасын, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер тапкыр түләнә торган түләүнең калган өлешен күчерү буенча реквизитлар

ТР буенча ФКИ ,ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы)
ИНН 1659036508
КПП 165901001
и-х/с 40101810800000010001
ТР Үзәк Банкының Казан шәһәрендәге бүлеге
БИК 049205001
ОКТМО ятманы эшкәртү урыны буенча күрсәтелә
Бюджет классификациясе коды һәм түләүнең билгеләнеше:
1 КБК 701 1 12 02102 02 0001 - «Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына конкурста (аукционда) катнашу өчен җыемнар»
120 (аукционда катнашу өчен җыем)
2 КБК 701 1 12 02012 01 0000 - «Җир асты байлыкларыннан файдалану өчен бер тапкыр түләү»
120 (бер тапкыр түләүнең калган өлеше)
3 КБК 701 1 08 07082 01 1000 - «Дәүләт пошлинасы»
110 (лицензия биргән өчен җыем)

Вакытлыча файдалану өчен һәм кире кайтарылырга тиешле акча күчерү реквизитлары (бер түләнә торган түләүнең алдан түләнә торган өлешен кертү өчен)

ТР Финанс министрлыгы ,ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы
ЛР 007010003-МинЭкиПР
«АК БАРС» БАНК ААҖ Казан шәһәре
и-х/с 40302810100020000798
кор/сч 30101810000000000805
БИК 049205805
ИНН 1659036508
КПП 165901001